БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 07 2024 ел № 176

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге « Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы» 299 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 24 июнендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31маендагы«Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең Хезмәткә түләү шартлары турындагы» 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 454 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга :

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге «Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы» 299 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге «Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы» 299 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге «Балтач муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы» 299 номерлы карары белән расланган Балтач муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Балтач муниципаль районы мәгариф оешмалары җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең гомуми тармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында күрсәтелгән карар белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 14 сентябрендәге «Балтач

муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турындагы» 299 нчы номерлы карары белән расланган Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Балтач муниципаль районы сайтында (baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов